РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**от 23 мая 2019 года** **г.Чистополь** **№ 44/5**

Чистай муниципаль районы
Советының 2018 елның 18 июлендәге
35/5 номерлы карары белән
расланган «Күмәк тыңлаулар
(иҗтимагый фикер алышу) оештыру
һәм уздыру тәртибе турындагы
Нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе дәүләт комитетының әйләнә-тирә мохитне саклау буенча 2000 елның 16 маендагы 372 номерлы боерыгы белән расланган, Россия Федерациясе территориясендә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү турындагы нигезләмәгә таянып, Чистай муниципаль районы Советы

**Карар бирә:**

1.Чистай муниципаль районы Советының 2018 елның 18 июлендәге 35/5 номерлы карары белән
расланган «Күмәк тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышу) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә»гә (Чистай муниципаль районы Советының 2019 елның 6 февралендәге 41/2 карары редакциясендә) 15 статьяга киләсе 2 эчтәлекне өстәп, үзгәрешләр кертергә:
«2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә әйләнә-тирә мохиткә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең йогынтысын бәяләү буенча, җәмәгатьчелек фикер алышуын оештыру буенча җаваплы орган - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты.».

2. Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районы рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының законлык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы Башлыгы Д.А. Иванов